**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 444 13 май 2015 ел

"Балаларны мәктәпкәчә белемнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына исәпкә кую һәм күчерүгә" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 10.03.2015 елның 1389/15 номерлы боерыгы нигезендә «Балаларны мәктәпкәчә белемнең (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына исәпкә кую һәм аларны кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының якынча формасын раслау турында һәм Нурлат муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне оештыруны камилләштерү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районында "Мәктәпкәчә белемнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымта итеп бирелә торган административ регламентын расларга.
2. Нурлат муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә рәсми сайтларда Нурлат муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын урнаштырырга.
3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 22.06.2012 ел, № 679 карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм күчерү " муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары Л. Н. Маняповка йөкләргә.

Руководитель А.К. Габдуллин